**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«_28_»_06_ 2021 ел Яр Чаллы № _84_

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегенең 16:39:010301:834 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт итү төренә үзгәртү буенча халык тыңлауларын үткәрү турында

РФ Шәһәр төзелеше кодексының 35, 36, 39 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, район Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып, район һәм Мәләкәс авыл җирлегендә яшәүчеләрнең уңайлы тормыш шартларына хокукларын, Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хуҗаларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатыннан,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегенең 16:39:010301:834 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт итү төренә үзгәртү буенча халык тыңлауларын үткәрү турында.

2.1. Әлеге карарны районның рәсми сайтында (tukay.tatar.ru) һәм Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитетының мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

2.2 Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты Юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.

3. Халык тыңлауларын бер көндә, 2021 елның 3 августта 13.00 сәгатьтә үткәрергә, үткәрү урыны: Тукай районы, Мәләкәс авыл җирлеге, Мәләкәс авылы, Молодежная урамы, 20.

4. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы итеп Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы А.Н. Нәдершинны билгеләргә.

5. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашу тәртибен кушымтадагыча расларга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Муниципаль район Башлыгы Ф.М. Камаев

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2021 елның 28.06 84 номерлы карарына кушымта

Гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибе

Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегенең 16:39:010301:834 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт итү төренә үзгәртү буенча фикер алышуларда халыкның катнашуын тәэмин итү максатында эшләнгән һәм авыл җирлеге халкының проект буенча фикер алышуда катнашу, шулай ук халык фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашуы халык тыңлауларында катнашу һәм авыл җирлеге халкының проект буенча тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә Тукай районы Башкарма комитетына җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Проектның график һәм текст рәвешендәге материаллары Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Мәләкәс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылган.

3. Проект буенча материаллар белән танышу вакыты: дүшәмбе – җомга 9.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр (12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр төшке аш).

4. Проект Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

5. Проект буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2021 елның 2 июлдән 2021 елның 2 августка кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46 йорт, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 кабинет.

6. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук гражданнарның проект буенча тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.

7. Халык тыңлаулары секретаре проект буенча фикерләрне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.

8. Халык тыңлаулары башланганчы, секретарь халык тыңлауларында катнашучыларны терки. Теркәү битендә халык тыңлауларында катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны күрсәтелә.

9. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:

- чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә;
- проект буенча фикер алышуга – 3 минутка кадәр;
- фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.

10. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла. Беркетмәгә халык тыңлауларын оештыручы һәм секретарь имза куя.

11. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме;

- халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны;
- халык тыңлауларында катнашкан авыл җирлеге гражданнарының саны;
- халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

12. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм ул халык тыңлаулары беркетмәсе белән бергә мәҗбүри рәвештә «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырылырга һәм районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.